# БӘХЕТ СЕРЕ

1. Һәр көн иртән уяталар
Иркәләп, сөеп.
Син бит минем күгәрченем,
Кояшым диеп.
Мин дә аларны сәламлим
Елмаеп-көлеп

Кушымта:
Уңъягымда – әнием,
Сулъягымда – әтием.
Алар белән мин бәхетле,
Рәхәт үтә һәр көнем.
Һәрчак шулай булсын диеп
Теләкләр телим.

2. Иркә гөлдәй үстерәләр
Назларга төреп.
Мин дә аларга эндәшәм
Әнием, әтием диеп.
Яратырмын сезне шулай
Гомергә сөеп.

Кушымта:
Уңъягымда – әнием,
Сулъягымда – әтием.
Алар белән мин бәхетле,
Рәхәт үтә һәр көнем.
Һәрчак бергә булыйк диеп
Теләкләр телим.

3. Өйләр ямьле, ашлар тәмле
Сез булганга
Мин бәхетле – әни янда,
әти янда
Тыныч, якты күкләр телим
бар җиһанга
Балаларның шат авазы

– дәва җанга

Кушымта:
Уңъягымда – әнием,
Сулъягымда – әтием.
Алар белән мин бәхетле,
Рәхәт үтә һәр көнем.
Илләр тыныч булсын  диеп
Теләкләр телим.